КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1404

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатория тикшерүләрен һәм башка сынауларны үткәрү буенча хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 01 сентябрь, 80 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатория тикшерүләрен һәм башка сынауларны үткәрү буенча хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 01 сентябрь, 80 нче карарына, преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүнең иң чик күләмен билгеләү тәртибе турында» 2011 ел, 31 март, 244 нче карары белән расланган республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм

мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүнең иң чик күләмен билгеләү тәртибенең 1.2 нче пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән расланган республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенең 12 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин